СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Куркачи, ул.Клубная, 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАНАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб урамы, 4

тел./факс 8(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
30 сентября 2020 г.

КАРАР
№ 4

Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 110 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 нче номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре күләмен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары, Иске-Казан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 110 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» (Советның 04.10.2018 № 131 карары редакциясендә) карары белән расланган Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Башлыгының айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 110 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» (Советның 04.10.2018 № 131 карары редакциясенә) карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 2020 елның 1 октябреннән аларның вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Әлеге Карарның 2 пункты нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи

окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 110 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» (Советның 04.10.2018 № 131 карары редакциясендә) карары белән расланган 2 нче номерлы кушымтаны, таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Башлыгының акчалата түләү күләме»

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 төркем |
| Авыл җирлеге Башлыгы | 15759 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Г.Р.Закирова